СОВЕТ БОЛЬШЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** Зур Тигәнәле ав. **КАРАР**

29.01.2024 № 66

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге, муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат, (хуҗалык алып бару хокуыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтне арендага бирү Тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче зат хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга бирелә торган мөлкәт исемлегенә кертелгән дәүләт мөлкәтен арендага бирү Тәртибен һәм шартларын раслау турында" 2016 елның 23 декабрендәге 976 номерлы карары белән,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 25 мартындагы 170 номерлы "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 23.12.2016 елның 976 номерлы карары белән расланган,Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче зат хокукларыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек инфраструктурасын тәшкил итүче субьектларга һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга арендага бирү Тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында" карары,Татарстан

Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Уставы белән,

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының 18.11.2019 ел, № 138 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге, муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат, (хуҗалык алып бару хокуыннан, оператив идарә итү хокукыннан,шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтне арендага бирү Тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.2. Аренда түләүләре күләме коммуналь хезмәтләр өчен түләү, техник хезмәт күрсәтү, арендага бирелгән мөлкәтне саклау һәм бирелгән мөлкәтне тоту һәм эксплуатацияләү белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган башка чыгымнарны, шулай ук мөлкәтне мәҗбүри иминиятләштерү чыгымнарын, күчемсез милек объекты астындагы җир кишәрлегеннән файдалану өчен түләүне үз эченә алмый.";

1.2. 3.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.3. Милекне арендага алу буенча ташлама милекне арендалаучы һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары булган яки социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре, Россия Федерациясенең башка билгеләнгән дәүләт программалары (подпрограммалары), Татарстан Республикасының дәүләт программалары (подпрограммалары), муниципаль программалар (подпрограммалары) белән билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирелә. Күрсәтелгән ташлама түбәндәге күләмдә аренда хакын билгеләүдән гыйбарәт:";

1.3. 3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.4. Әлеге Тәртипнең 3.3 пунктында каралган шартларда төзелгән мөлкәтне арендалау килешүен вакытыннан алда өзгәндә, арендаторның мөлкәтне арендалау килешүе буенча йөкләмәләрен үтәмәве яисә арендатор әлеге Тәртипнең 3.3 пунктында каралган критерийларга туры килмәсә, дәүләт милкеннән файдалануның бөтен срогы 100 процент күләмендә түләнергә тиеш-

мөлкәтне арендалау килешүендә аны төзү хокукына сату нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда бәясеннән процент күләме.".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча:https://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **М.Ә.Гатин**